# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре № 284-38 «20» август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 30.03.2018 ел, №177-27 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлау нормативларын раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында
(13.12.2018 №222-32, 23.05.2019 №266-36 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 29.05.2019 ел, №116-ФЗ Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Җир кодексын үтәү максатыннан, урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрдә урманнарны саклауны тәэмин итү белән бәйле «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел № 538-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 30.03.2018 ел, №177-27 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлау нормативларын раслау турында» карары белән расланган,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына(13.12.2018 №222-32, 23.05.2019 №266-36 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 бүлектә:

а) 4.2.1 пунктның дүртенче абзацында «бакчачылык (дача)» сүзләрен «бакча җирләре» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4.2.34 пунктының беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Аны торак бинадан торак булмаган бинага күчергәннән соң, торак биналарга керү мөмкинлеген тәэмин итүче биналардан файдалану мөмкинлеге төшереп калдырылырга тиеш.».

1.2. 4.7 бүлектә:

а), 4.7.2, 4.7.3 пунктларда «дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 5.1 бүлектә:

а) 5.1.3 пунктның беренче абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек берләшмәләре, дача хуҗалыклары» сүзләрен «бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләр, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнар тарафыннан булдырылган коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 5.2 бүлектә:

а) 17 таблицаның «җир кырыннан ераклык да ким булмаган» сүзләрен «бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 7.3 бүлектә:

а) 7.3.22 пунктта:

- икенче абзацта «(урман парклары)» сүзен төшереп калдырырга;

- өченче, дүртенче һәм бишенче абзацларда «(урман парклары)» сүзен төшереп калдырырга» ;

б) 7.3.23 пунктта «(урман паркларында)» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 7.3.27 пунктта «(урман парклары)» сүзен төшереп калдырырга

1.6. Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларында №1 кушымтаның «Федераль законнар» бүлегендә:

а) 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 29.07.2017 ел № 217-ФЗ Федераль закон;».

1.7. Азнакай муниципаль районының төзелеш проектлаштыру Нормативларына 3 нче кушымтаның 4 нче таблицасында:

а) V бүлекнең «Сәүдә объектлары, шул исәптән: киосклар, павильоннар, кибетләр, сәүдә үзәкләре, сәүдә комплекслары» диган 5 графада «бакчачылык һәм

дача берләшмәләре» сүзләрен «бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләр, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнар тарафыннан булдырылган коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

1.8. Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру Нормативларына №9 кушымтаның 1, 2, 3, 4 таблицаларында «(урман парклары)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен Азнакай район Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин